КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 март г.Казань № 153

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 декабрь, 622 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 декабрь, 622 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1295 нче; 2020 ел, 27 май, 426 нчы; 2020 ел, 1 сентябрь, 770 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1019 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктның егерме беренче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.4 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы $3^3$ өлешендә һәм 54 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш) проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлеше нигезендә эшләр башлану турында хәбәрнамә алган датадан төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы $3^8$ һәм $3^9$ өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документларын кертеп) таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектын кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләренә туры килү турында бәяләмә (алга таба – туры килү турында бәяләмә) биргән датага кадәр экспертиза ясалырга тиешле капиталь төзелеш объектларын төзегәндә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.4 пункт өстәргә:

«4.4. Инспекциянең вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $20.6^1$ статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы.»;

5.1 пунктның икенче абзацында татар текстында «килештерү» сүзеннән соң «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 4 өлеше һәм» сүзләрен өстәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктындагы бишенче, алтынчы абзацлары 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була;

әлеге карарның 1 пунктындагы бишенче, алтынчы абзацларының гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 декабрь, 622 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 апрель, 299 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин